КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 1 сентябрь г.Казань № 653

Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктларын булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау турында

Балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктларын булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу механизм карарга теркәлгән Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктларын булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктлары булдыра торган Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр исемлеген расларга;

2025 елның 1 ноябреннән яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктларын булдыр булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыруны оештырырга.

4. Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр базасында булдырылган яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктлары хезмәтләрен күрсәтү буенча чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максат өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль

яклау министрлыгына каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 1 сентябрь, 653 нче
карары белән расланды

# Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктларын булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыру турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктын (алга таба – прокат пункты) булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру тәртибен, прокат пунктларында балалы гаиләләргә яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар бирү тәртибен һәм шартларын җайга сала.

1.2. Прокат пункты Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр (алга таба – ХСХККҮ) базасында төзелә, аларның исемлеге Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан раслана.

1.3. Прокат пункты балалы гаиләләрнең кайбер категорияләрен яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар белән вакытлыча тәэмин итү максатларында булдырыла.

1.4. Прокат пункты ХСХККҮ директоры боерыгы белән оештырыла.

## II. Прокат пунктында яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар алу хокукына ия гражданнар категорияләре

2.1. Прокат пунктында яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар алу хокукына гражданнарның түбәндәге категорияләре арасыннан яшь ярымга кадәр балалар тәрбияләүче (ата-аналарның һәм балаларның Россия Федерациясе гражданлыгы булганда, прокат пункты урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районында, шәһәр округында бала һәм аның ата-анасы (бердәнбер атасы йә анасы) даими яисә вакытлыча яшәү шарты белән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булмаганда), бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле ай саен пособие алучы ата-аналар ия:

һөнәри белем бирү оешмаларының яисә югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге бүлектә укучы 25 яшькә кадәрге студентлары (ата-ананың икесе дә);

күпбалалы яшь 30 яшькә кадәрге ата-аналар (ата-ананың икесе дә);

ялгыз ана (ялгыз ата).

## III. Прокат пунктын булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру тәртибе

3.1. Прокат пунктының эшчәнлеген оештыру өчен ХСХККҮтә яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар үрнәкләрен карау өчен махсус җиһазландырылган бүлмә (бүлмәнең бер өлеше), яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны саклау урыны бирелә, мәгълүмат бирү характерындагы стенд рәсмиләштерелә.

3.2. ХСХККҮ директорының боерыгы белән прокат пункты эшен оештыру өчен, шул исәптән яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны кабул итү, саклау һәм гражданнарга тапшыру өчен матди җаваплы кеше (алга таба – ХСХККҮ белгече (җаваплы кеше)) билгеләнә.

3.3. ХСХККҮ белгеченең (җаваплы затның) яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны эксплуатацияләү буенча кирәкле белемнәре, күнекмәләре, осталыгы булырга тиеш.

3.4. Прокат пунктын җиһазландыру түбәндәгеләр исәбеннән башкарыла:

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында ХСХККҮ базасында булдырылган прокат пунктлары хезмәтләрен күрсәтүгә каралган акча;

ХСХККҮнең эшмәкәрлек һәм башка керем китерүче эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

гражданнаныңр һәм юридик затларның ирекле иганәләре;

гамәлдәге законнар белән тыелмаган башка чыганаклар.

3.5. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны ремонтлау ХСХККҮ тарафыннан иганә (хәйрия) ярдәменнән алынган акча, эшмәкәрлек һәм башка керем китерә торган эшчәнлек гамәлгә ашыру, гамәлдәге законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.6. ХСХККҮ белгече (җаваплы зат) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар бирү тәртибе һәм шартлары мәсьәләләре буенча гражданнарга консультация бирү;

яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар алуга гариза биргән гражданнар, яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар бирү һәм кире кайтару исәбен алып бару;

прокат пунктында гражданнарга яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны сайлауда ярдәм күрсәтү;

гражданнарга яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны куллану, саклау һәм куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре турында мәгълүмат бирү.

3.7. Прокат пункты эшчәнлеген контрольдә тотуны ХСХККҮ директоры башкара.

3.8. Прокат пункты тарафыннан бирелә торган яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларның тәкъдим ителә торган исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелә.

3.9. Прокат пунктында ХСХККҮ исеме, урнашу урыны һәм эш режимы күрсәтелгән элмә такта булырга тиеш.

3.10. Прокат пунктының эше турында мәгълүмат мәгълүмат стендында һәм ХСХККҮ сайтында урнаштырыла.

Прокат пункты турында мәгълүматта түбәндәгеләр булырга тиеш:

прокат пунктының эш режимы;

вакытлыча файдалануга бирелә торган яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар исемлеге;

яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны прокатка бирү тәртибе һәм шартлары;

яңа туган балалар өчен бирелгән беренче кирәк-ярак предметларны файдалану кагыйдәләре.

## IV. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү тәртибе

4.1. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү нигезе – ХСХККҮкә баланың ата-анасыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны вакытлыча файдалануга бирү турында гариза (алга таба – гариза) керә, аңа түбәндәгеләр теркәлә:

гариза бирүче һәм аның ире (хатыны) шәхесен һәм яшен раслый торган документлар;

прокат пункты урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районында, шәһәр округында баланың һәм аның ата-анасының (йә атасының, йә анасының) даими яисә вакытлыча яшәвен раслый торган документлар;

бала (балалар) туу турында таныклык;

һөнәри белем бирү оешмасыннан яки югары белем бирү мәгариф оешмасыннан ата-аналарның һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге бүлектә укулары турында белешмә кәгазе (никахлашкан гаиләдә ата-ананың икесе дә яисә тулы булмаган гаиләдә йә атасы, йә анасы һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге бүлектә белем алучы гаиләләр өчен);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында иминләштерелгән затның шәхси кабинеты аша билгеләнгән социаль түләүләр һәм ташламалар турында алынган белешмәләр;

күпбалалы гаилә таныклыгы (күпбалалы гаиләләр өчен);

граждан хәле актларын язу органы яисә күпфункцияле үзәк тарафыннан Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яисә булмавын раслый торган белешмә кәгазьләре һәм башка документлар формаларын һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яисә булмавын раслый торган белешмә кәгазьләре һәм башка документлар формаларын тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы боерыгы белән расланган 2 нче форма буенча бирелгән туу турында белешмә кәгазе (ялгыз аналар (аталар) өчен);

ата-аналарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә кәгазе.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булса, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм ХСХККҮ белгече тарафыннан таныклана.

4.2. ХСХККҮ белгече (җаваплы зат) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза һәм аңа теркәлә торган документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүне һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча гаризаларны теркәү журналында теркәүне:

шәхсән кабул иткәндә – гариза һәм документлар кергән көнне;

гариза һәм документлар почта аша кергәндә – гариза һәм документлар ХСХККҮкә кергән көнне. Гариза һәм документлар ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә кергән очракта – ХСХККҮнең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килә торган беренче эш көнендә;

гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә гариза һәм документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында расписка кәгазен бирү – гариза һәм документлар кергән көнне, гариза почта аша җибәрелгәндә гаризаны теркәү датасы һәм бирелгән керү номеры турында хәбәрнамә җибәрү – ХСХККҮкә гариза кергән көннән соң килә торган бер эш көне чыкканга кадәр.

4.3. ХСХККҮ белгече (җаваплы зат) гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кергән көннән алып өч эш көне эчендә аларны карый, яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә гаризаны карау нәтиҗәләре турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү турында карар кабул иткәндә, хәбәрнамәдә шулай ук гариза бирүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча ХСХККҮ һәм баланың ата-аналарының берсе (йә атасы, йә анасы) арасында төзелә торган яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзү өчен килергә тиешле срок күрсәтелә. Әлеге срок гариза бирүчегә хәбәрнамә килгән көннән алып өч эш көненнән ким булмаска тиеш.

4.4. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез:

әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән документларны (документлар күчермәләрен) тапшырмау яисә тулы күләмдә тапшырмау;

дөрес булмаган белешмәләр булу;

срогы гамәлдән чыккан документларны тапшыру;

проект пунктында яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар булмау;

ата-аналарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлары булу.

4.5. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү шартнамәдә күрсәтелгән срок эчендә гамәлгә ашырыла.

Килешү шартлары буенча ата-аналарга бирелгән яңа туган балалар өчен вакытлыча файдалануга бирелгән беренче кирәк-ярак предметларны үз билгеләнүе буенча куллану бурычы йөкләнә.

Граждан тарафыннан яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны файдалану кагыйдәләре бозылуаркасында килеп чыккан кимчелекләр ачыкланган очракта, яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны ремонтлау яисә аларның бәясе, амортизацияне исәпкә алып, граждан тарафыннан үзенең шәхси акчасы исәбеннән түләнелә.

4.6. Шартнамә төзү өчен граждан әлеге Нигезләмәнең 4.3 пункты нигезендә хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокта килмәгән очракта, гариза бирүче шартнамә төзүдән баш тарткан дип санала. Шул ук вакытта ХСХККҮ белгече (җаваплы зат) шартнамә төзү өчен гариза бирүче килергә тиешле срок тәмамланган көннән өч эш көне эчендә бу хакта гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (телефон аша, язма рәвештә почта адресы яки электрон почта адресы буенча) хәбәр итә.

4.7. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокат пунктының урнашу урыны буенча бирелә.

4.8. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар бары эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган куллану максатларында (өченче затларга тапшыру хокукыннан башка) бирелә.

4.9. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны прокат пунктыннан бирү һәм аларны прокат пунктына кире кайтару Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны кабул итү-тапшыру акты буенча башкарыла.

4.10. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар төзек хәлдә, куллануга яраклы итеп бирелә. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны биргәндә ХСХККҮ белгече (җаваплы зат) гражданны яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны куллану буенча инструкция белән таныштыра.

Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларның төзеклеген тикшерү граждан катнашында үткәрелә.

4.11. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларга ихтыяҗ аларны бирү мөмкинлегеннән артып киткән очракта, яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү ХСХККҮ белгече (җаваплы зат) тарафыннан ХСХККҮкә гариза кергән датадан чыгып төзелә торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.12. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокат пунктына кабул ителгәннән соң яки кире кайтарылганнан соң, алар дезинфекцияләнергә тиеш.

4.13. Шартнамәне вакытыннан алда өзү шартлары:

граждан тарафыннан шартнамәдә шартлар бозылу;

ХСХККҮ бетерелү (эшчәнлеге туктатылу);

ата-ананың (ата-аналарның) һәм (яки) баланың вафат булуы;

граждан тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында китерелгән яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар бирүгә нигезләрен югалту.

## V. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү сроклары һәм шартлары

5.1. Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларны бирү срогы шартнамәдәге яклар килешүе белән, әмма бала әлеге Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән яшькә җиткәнгә кадәр билгеләнә.

5.2. Беренче кирәк-ярак предметлар вакытлыча файдалануга бушлай бирелә.

Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметлар прокаты пунктларын булдыру буенча пилот проектны гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә кушымта

Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметларның
тәкъдим ителә торган исемлеге

| Т/с | Яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предметның исеме | Түбәндәге яше тулганга кадәр яңа туган балалар өчен беренче кирәк-ярак предмет бирелә торган бала яше |
|---|---|---|
| 1. | Трансформер коляска | 1,5 яшь |
| 2. | Балалар караваты | 1,5 яшь |
| 3. | Йөрү җайланмасы | 2025 ел |
| 4. | Кышкы чана коляска | 1,5 яшь |
| 5. | Баланы пеленкага төрү өстәле | 6 ай |
| 6. | Ашату өчен урындык | 1,5 яшь |

___